**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Уразай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Уразай авылы №65 "23" июнь 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 гыйнварындагы 57 нче номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы « Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (21.11.2016 №48, 04.09.2017 №66, 02.07.2018 №103,12.03.2019 №131-4, 18.02.2020 №165-23, от 10.08.2021 №35, от 16.11.2021 №41 карарлар редакциясендә)

Муниципаль норматив хокукый актларны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына туры китерү максатыннан һәм 2021 елныц 01июлендәге 276-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында», 2021 елның 30 апрелендәге 476-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» , 2021 елның 30 декабрендәге 123-ФЗ номерлы «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» фееараль законнарны, «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» Федераль законның 1 статьясын үтәү йөзеннән һәм «Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү тәртибе турында нигезләмәне гамәлгә кертү тәртибе хакында» Россия Федерациясе Югары Советы карарының һәм Россия Федерациясе закон актларыныц аерым нигезләмәләренең, үз көчләрен югалтуын танып, Россия Федерациясе Хокүмәтенең 2022 елның 20 апрелендәге 711 номерлы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенец кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларыныц үз көчләрен югалтуын тану турында» карары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 гыйнварындагы 57 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының 2022 елның 15 июнендәге 63 нче номерлы Азнакай муниципаль районы « Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәлә вәкаләтләре кабул итү турында карары нигезендә

Уразай авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 гыйнварындагы 57 нче номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы « Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (21.11.2016 №48, 04.09.2017 №66, 02.07.2018 №103,12.03.2019 №131-4, 18.02.2020 №165-23, от 10.08.2021 №35, от 16.11.2021 №41 карарлар редакциясендә)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 27 статьяның 5 пунктындагы 6 пунктчасына «, блокланган төзелеш йортларының берсен реконструкцияләгән очракта, бер рәттә барлык йортларның да хокук ияләренең ризалыгы» сүзләрен өстәргә.

1.2. 27 статьяның 9 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзелеш этабы дигәндә бер җир кишәрлегендә төзү, реконструкцияләү планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектлары арасыннан капиталь төзелеш объектын төзү яисә реконструкцияләү аңлашыла, әгәр мондый объект әлеге җир кишәрлегендә капиталь төзелеш объектын төзү яисә реконструкцияләүгә бәйсез рәвештә (ягъни әлеге җир кишәрлегендә бүтән капиталь төзелеш объектларын төзү яки реконструкцияләү), капиталь төзелеш объектын төзү яисә реконструкцияләү, ул автоном рәвештә кулланылышка кертелергә һәм эксплуатацияләнергә мөмкин (ягъни әлеге капиталь төзелеш объектының башка өлешләрен төзүгә яисә реконструкцияләүгә бәйсез рәвештә), шулай ук төзелеш объектын (капиталь төзелеш объектын төзү объектын) урнаштыру, биналарны, корылмаларны сүтү һәм күчерү, инженерлык коммуникацияләрен, төзелеш биналарын төзү һәм башка эшләрне үз эченә алган җир кишәрлекләреннән файдалану хокукын рәсмиләштерү үз эченә ала торган төзелеш территориясен әзерләү эшләре комплексы. Инфраструктура объектлары исемлегенә кертелгән транспорт инфраструктурасының линияле объектларына карата төзелеш этабы астында шулай ук шундый линия объекты составына керә торган һәм автоном файдалануга кертелә алмый торган бер яки берничә капиталь төзелеш объектын яисә аларның өлешләрен төзү, реконструкцияләү шулай ук аңлашыла. Җитештерү билгеләнешендәге объектларга карата төзелеш этабында шулай ук территорияне планлаштыру, төзекләндерү, яшелләндерү һәм яктырту эшләре комплексы да аңлашыла.».

1.3. 27.1 статьяның 1 пунктында «Индивидуаль торак төзелеше объектын төзү яисә реконструкцияләү максатларында» сүзләреннән соң «күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүдән тыш» сүзләрен өстәргә.

1.4. 29 статьяның 3 пунктындагы 6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6) төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектын инженер-

техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) турында акт (бу объектны мондый тоташтыру (технологик тоташтыру) проект документациясе тарафыннан каралган очракта);».

1.5. 36 статьяның 11 пунктында:

а) өченче абзацта «эшләр башкару» сүзләрен « җир асты байлыкларыннан файдалану» сүзләренә алмаштырырга;

б) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Җир асты байлыкларының аерым участокларыннан файдалану ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү, җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау, әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында чикләнергә яисә тыелырга мөмкин. Торак пунктлар һәм территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар территорияләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану халыкның тормышы һәм сәламәтлеге иминлеге, әйләнә-тирә мохитне саклау куркынычы тудырырга, тау эшкәртмәләренең, бораулау скважиналарының һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмаларның сакланышын да кертеп, биналарның һәм корылмаларның сакланышын булдырырга мөмкин булган очракларда чикләнергә яисә тыелырга мөмкин. Махсус сакланылучы табигать территорияләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану аларның территорияләрен махсус саклау режимы нигезендә гамәлгә ашырыла. ("Җир асты байлыклары турында" законның 8 статьясы).

2. Әлеге карарның 1.2 пункты 2022елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә .

3. Әлеге карарны«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: А.М.Шэрифуллина